# Мәүлид аенда укый торган

Запись Масгуды Шамсутдиновой




Дин кардәшләр, сөенеч безгә, изге Мәүлид ае килде,
Шатлык тулсын йөзебезгә, изге Мәүлид ае килде.
Шушы айда Рәсүл тугды, дөнъяга нур балкып торды,
Ачты безгә тугры хак юл, изге Мәүлид ае килде.
Бу ай безгә бик зур бәйрәм, дөнъяга ул бер бик зур ямь
Хөрмәт итсәк чын күңелдән, изге Мәүлид ае килде.
Кадерле ай бу ай безгә, Иман нуры йөзебездә,
Аллаһыдан бүләк безгә, изге Мәүлид ае килде.
Һәммә пигамбәрләрдин артык Син сөекле Аллага,
Безгә күрсәтте бәхетләр, тугры юлны бәндәгә.
Менә бүген Мәүледеңә җыелыштык, и Рәсүл,
Тезелешеп барчабызга кыйл шәфәгать, дип, Рәсүл.

©